РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Каенлинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423560, Нижнекамский район,
с. Каенлы, ул. Ленина, 44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге
Советы

423560, Түбән Кама районы,
Каенлы авылы, Ленин урамы, 44

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp @tatar.ru, сайт: www. kaenlinskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 15 октябреннән № 18

**«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Каенлы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1.«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2.Әлеге карар «Туган як» газетасында рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе нигезендә халыкка җиткерелә.

3.Аның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Каенлы
авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге Советының
2020 елның 15 октябрендәге
18 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда гражданнар
җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уткәрү тәртибе турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә эшләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Халык җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пунктта яшәүчеләр, даими яки күбесенчә аның территориясендә яшәүчеләр, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия кешеләр катнаша ала.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ихтыярый һәм ирекле.

1.4.Гражданнар җыенда шәхсән үзе катнаша һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Халык җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатыннан үткәрелә.

## Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

күрсәтелгән торак пункт территориясенбашка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерә торган, күрсәтелгән торак пункт аның составына кертелгән торак пунктта җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

сайлау хокукына ия булган җирлектә яшәүчеләр саны 100 дән артык кеше булса,муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә җирлекнең вәкиллекле органын төзү, аның саны һәм вәкаләтләр вакыты турында мәсьәлә буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

җирлек составына керүче торак пунктта, шәһәр эчендәге район, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, шәһәр округы яисә муниципаль район чикләрендә урнашкан авылара территориядә әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

авыл җирлегенең түбән тыгызлыгы булган территориядә урнашкан яки керергә авыр булган җирлектә, әгәравыл җирлегенең халык саны 100 кешедән артмаган очракта, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча.

Авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә, конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.7. Гражданнар җыенын уздыру Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.8. Җыенга әзерлек һәм аны үткәрү белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Халык җыены үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта халык җыенын үткәрү инициативасы кемнәрдән булырга мөмкин:

- муниципаль берәмлек башлыгы;
- сайлау хокукына ия булган, саны 10 кешедән ким булмаган, гражданнар җыенында катнашырга хокуклы торак пунктта яшәүчеләр төркеме, ягъни даими яки

күбесенчә торак пункт территориясендә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткәнРоссия Федерациясенең эшкә сәләтле гражданнары, шулай укРоссия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда хокукларга ия булган һәм торак пункт территориясендә даими яисә күбесенчә яшәүче чит ил гражданнары.

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имзалар кәгазе (1 нче кушымта) яисә анда гражданнар җыены үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителгәнинициатив төркем җыелышының беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә тиеш, аларда күрсәтелгән булырга тиеш:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

гражданнар җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты;

гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы; паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе һәм номеры, яшәү урыны адресы, аның имзасы һәм имзасын кертү датасы.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, даими яки күбесенчә яшәүче, торак пункт территориясендә теркәлгән гражданнар саныннан 5 процентын тәшкил итә, ләкин 25 имзадан да ким була алмый.

2.4. Имзалар кәгазьләре имзалар җыючы зат тарафыннан таныклана, таныклау датасын, фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, паспорт яки аны алыштыручы документ номерын һәм сериясен, яшәү урыны адресын күрсәтеп, муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

## Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән (2 нче кушымта), ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы белән – муниципаль берәмлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта) барлык кирәкле документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы аның максатка ярашлы булмавы сәбәпләре буенча гражданнар җыенын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Халык җыены мәсьәләсе аны төрле яклап аңлату мөмкинлеге булмаслык итеп формалаштырылырга тиеш, ягъни аңа бары тик бертөсле җавап кына бирергә мөмкин булырга тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү, аны күчерү турындагы карар муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә басылып чыга (халыкка җиткерелә).

Гражданнар җыенын уздыру турында муниципаль берәмлек башлыгы карарында яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарындатүбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә;

гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы-муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында белешмәләр.

2.9. Гражданнар җыенын (муниципаль берәмлек башкарма комитеты) әзерләү һәм уздыру өчен җаваплы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе, гражданнар җыенын үткәрү турында муниципаль берәмлек башлыгы карары яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендәсайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлекләрен төзи; гражданнар җыенына мәгълүмат материаллары әзерли; муниципаль берәмлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәмбашка ысуллар беләнгражданнар җыены турында хәбәр итә (4 нче кушымта).

Муниципаль берәмлек башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәрү өчен биналар бирергә тиеш.

2.9.1. Торак пунктта яшәүчеләргә халык җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карар, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыенына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

2.9.2.Гражданнар җыенының һәр катнашучысы гражданнар җыенын үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлек башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыенын үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыенын уздыру датасын күчерү турында караржыен үткәрү билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1.Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән җыенда катнашучы һәм сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтле заты тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2.Җыенда катнашырга теләк белдергән,хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан башка гражданнар, җыенда тикшерелә торган мәсьәләләрне хәл итү аларның эшчәнлекләре белән бәйле булганпредприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре җыенга кертелә.

3.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче кеше теркәлергә һәм әлеге муниципаль берәмлек башлыгы ризалыгы белән җыенда катнашырга мөмкин.

3.4. Язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) гражданның шәхесен раслаучы документның(Россия Федерациясе гражданы паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һәм башкалар) булуы расларга мөмкин.

3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы. Кворум булмаганда,

гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелмәскә тиеш.

3.6. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә.

3.7.Яшерен тавыш бирү уздырганда,гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга тавыш бирү өчен бюллетень бирелә (5 нче кушымта).

3.8. Гражданнар җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яисә гражданнар җыенына теркәлгән катнашучылар санынннангади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән сайлап алынган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.9. Гражданнар җыены сәркатипне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны ике кешедән дә ким булырга тиеш түгел. Гражданнар җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә гражданнар җыенын чакыру инициаторлары тарафыннан кертелгән сораулар мәҗбүри рәвештә кертелә. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта карала. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.10. Гражданнар җыены җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне саклый, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.11. Гражданнар җыенында секретарь тарафыннан беркетмә алып барыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: җыен үткәрү датасы һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны (6 нчы кушымта).

3.12. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат һәм җыен секретаре тарафыннан кул куела һәм, гражданнар җыенында муниципаль берәмлек башлыгы рәислек итмәгән очракта, муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала, әгәр аның өчен сайлау хокукына ия җыенда катнашучы гражданнарның яртысыннан артыгы тавыш бирсә.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш (7 нче, 8 нче кушымталар).

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның җирлек уставы белән билгеләнгән,алар арасында вәкаләтләрне чикләү нигезендә үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә мөмкин яисә суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш һәм муниципаль хокукый актлар таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрне турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару) кирәк булса, күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару) алар компетенциясенә керә торган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

**Гражданнар җыены карарларын үтәү**

4.7. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

4.8. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның үтәлмәве закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә
**1 нче кушымта**

ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

Без, түбәндә имза куючылар, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге____________________________________торак пунктында____________________________________
____________________________________
мәсьәләсен формалаштырып,____________________________ гражданнар җыенын (гражданнар җыенын үткәрү сроклары) үткәрү инициативасын хуплыйбыз.

| т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры | Имза датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен таныклыйм ____________________________
(имза җыюны гамәлгә ашыручы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы,
____________________________________
яшәү урыны,
паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры)

____________________(имза һәм дата)

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда гражданнар
җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмәгә
2 нче кушымта


РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Каенлинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423560, Нижнекамский район,
с. Каенлы, ул. Ленина, 44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл жирлеге
Советы

423560, Түбән Кама районы,
Каенлы авылы, Ленин урамы, 44

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp @tatar.ru, сайт: www. kaenlinskoe-sp.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 00 _________ № __

**Гражданнарнынүзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге __________________ торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Каенлы авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге _________________торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 20__ елның ____________ билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2. «Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге_________________ төрак пункты территөриясендәяшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, I төркем инвалидлар, ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге (уку йортына йөреп уку) уку студентлары, __________ суммасында 20____ елда үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрергә сез ризамы:

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Каенлы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән әлеге карарны кабул ителгән көннән өч көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Каенлы авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Р. Гарипов

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда гражданнар
җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмәгә
3 нче кушымта


| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| Глава | Түбән Кама муниципаль районы |
| Каенлинского сельского поселения | Каенлы авыл жирлеге |
| Нижнекамского муниципального района | Башлыгы |
| 423560, Нижнекамский район, | 423560, Түбән Кама районы, |
| с. Каенлы, ул. Ленина, 44 | Каенлы авылы, Ленин урамы, 44 |

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp @tatar.ru, сайт: www. kaenlinskoe-sp.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 00 _________ № __

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге ___________________ торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Каенлы авыл җирлеге башлыгы карар бирде:

1. Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге _________________торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 20___ елның _____________ билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2. «Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге_________________ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган

яшәүчедән, I төркем инвалидлар, ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге (уку йортына йөреп уку) уку студентларыннан тыш, __________ суммасында 20____ елда үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрергә сез ризамы:

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Каенлы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән әлеге карарны кабул ителгән көннән өч көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Каенлы
авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда гражданнар
җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмәгә
4 нче кушымта

Сайлау хокукына ия Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге______________________ торак пунктында яшәүчеләр

ИСЕМЛЕГЕ

20___ елның «___» __________________

| т/с | Фамилиясе, исеме, атаының исеме | Туган елы (18 яшьтәгеләргә - туган числосы, ае) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ _______________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)
Гражданнар җыены секретаре _________ ________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда гражданнар
җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмәгә
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенә керүче _________ торак пунктында үзара салым кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү

**БЮЛЛЕТЕНЕ**

| | |
|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган мәсьәләнең эчтәлеге | «Әйе» ☐ |
| | «Юк» ☐ |
| | «Тавыш бирми калды» ☐ |

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда гражданнар
җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмәгә
6 нчы кушымта

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

______________________________________________________________

20__ елның«___» ____________ № _____

_____________________________________
(торак пункт исеме)

Катнаштылар __________________________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче_____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Гражданнар җыены секретаре _____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**
1.

2.

**Беренче мәсьәлә буенча тыңланды:**
_____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. _____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (теркәлә)
һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ЧЫГАРДЫЛАР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше
«Тавыш бирми калды» - ____ кеше
Карар__________________________
кабул ителгән (кабул ителмәгән)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңланды:**

___________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. __________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (теркәлә)
һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ЧЫГАРДЫЛАР**: (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «Әйе» - ____ кеше
«Юк» - ____ кеше
«Тавыш бирми калды» - ____ кеше
Карар ________________________
кабул ителгән (кабул ителмәгән)

Гражданнар җыенында рәислек итүче_________ __________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)
Гражданнар җыены секретаре_________ __________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда гражданнар
җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмәгә
7 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Түбән Кама**
**муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге**
**составына керүче _____________торак пунктында гражданнар**
**җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге_________________ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, I төркем инвалидлар, ветераннар, Боек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге (уку йортына йөреп уку) уку студентларыннан тыш, __________ суммасында 20____ елда үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрергә сез ризамы» мәсьәләсе буенча 20** елның _________уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелгән: 1)...; 2)... .

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә_______ гражданнар җыенында катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан _________гражданнар җыенда катнашучылар саны кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен_____ гражданнар җыенында катнашучы; «Юк» позиңиясе өчен ____ җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче____________ торак пунктында гражданнар җыенын узды дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче_________________ торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннары, Бөек Ватан сугышында

катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, __________ суммасында 20_____ елда Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге ________________ торак пунктында үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрергә сез ризамы» мәсьәләсе буенча карарны 1)...; 2)...кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Каенлы авыл җирлеге сайтында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районыныц Каенлы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _____________ ___________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе _______________ ____________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда гражданнар
җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмәгә
8 нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче ______________________________ торак пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

20__ елның «___» _____________ № _____

В соответствии со статьями 25.1, 56 Федерального закона «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», статьей 35 Закона Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә

______________________________________________________________________________
(торак пункт исеме)
гражданнар җыены **карар бирә:**

1.
2.
3.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ ____________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе __________ ____________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)